**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

**КАРАР**
**17.06.2020**

**КАРАР**
**№152**

**IV чакырылыш Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2007 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар бирде:

1. IV чакырылыш Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Сарман» газетасында бастырырга, кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

«Иске Имән авыл җирлеге»
МБ Советы рәисе Р.Ә. Исламова